**Сценарий муниципального конкурса чтецов произведений Гилемдара Рамазанова, посвященного 100-летию со дня рождения башкирского поэта, литературоведа, переводчика Литературно-поэтический вечер «Илем синең белән горурлана, яугир ага - шагыйрь Гыйлемдар!»**



**Фоновая музыка.**

Мәшәкатьләр белән йөрегәндә,
Атлап уздым туган кырларны,
Уяттылар алар күңелдәге
Йокымсырап яткан җырларны.
Шыбырдаша бодай башаклары:
Китмә әле, монда кал, диләр.
Тургай моңын, курай иңрәүләрен –
Барысын да җырга сал диләр.
Онытылды ыгы-зыгылар да
Җырларымның туган җирендә,
Үзем киттем, күңел торып калды
Мәңге яшәр кырлар иңендә.

Хәерле көн, кадерле дуслар, хөрмәтле кунаклар! Сезне Чакмагыш узәк биләмә-ара китапханәсенен уку залында күрергә бик шатбыз.

- Бүген бездә бәйрәм, матур бәйрәм. Без бүген бик бәхетле, чөнки бездә, безнең белән янәшәдә олы йөрәкле, гажәеп тә талантлы, киң күңелле якташларыбыз жыелган.

- Безнең Башкортостан, Чакмагыш ягы турында сүз кузгалганда, беренче булып аның кырлары, тугайлары, тугаенда сайраучы пар сандугачлары, шул сандугачлардан калышмаучы мәшһүр җырчылары күз алдына килеп баса. Алар турында бар доньяга бәян итүче шагыйрьләребез, язучыларыбыз бик күп.

Туган ягыбызның гүзәллеген, халкын данлап иҗат иткән талантлы якташ язучыларыбыз нын берсе - **Гилемдар Рамазанов**.

**Жыр. <u>Шат кояшлы Чакмагышым.</u>**

**Шагыйрь** - 1923 елның 16 июнендә Чакмагыш районы Иске Балак авылында туган. Мәктәптән соң Дәүләкән башкорт педагогия училищесын тәмамлаган. Бөек Ватан сугышында катнашучы Курск дугасында, Украинада сугышкан, Польша, Чехословакия, Германия, Австрия аша үткән II дәрәҗә Ватан сугышы ордены, ике Кызыл Йолдызнын ордены, хәрби бүләкләр белән бүләкләнгән.

1949-1950 елларда Бөрө шәһәренең укытучылар институтында һәм педагогия училищесында укыта. Мәскәү дәүләт университетының аспирантурасын тәмамлый, кандидатлык диссертациясен яклый. 1955-1958 елларда Г.Рамазанов «Совет Башкортостана» газетасының баш мөхәррире булып эшли. 1958 елдан гомеренең соңгы елларына кадәр РФ Фәннәр академиясенең БФ тарих, тел һәм әдәбият институтында өлкән фәнни хезмәткәр булып эшли. 1982 елда Г.Рамазанов әдәби хезмәтләре өчен С.Юлаев исемендәге Республика премиясенә лаек була.

**Жыр. Г.Салимова**

Кадерле дуслар! Бүген без **«Илем синең белән горурлана, яугир ага - шагыйрь Гыйлемдар!»** әдәби - шигъри бэйгегэ йомгак ясыйбыз. Бэйге 2023 елнын апрель аеннан октябрь аена тиклем барды. Конкурста 14 яшьтән өлкәнрәк теләүчеләр катнаша алды. Катнашуга район мәктәпләре укучылары, китапханә укучылары, яшьләр, өлкәннәр чакырылды.

Конкурс башкорт шагыйре, әдәбият белгече, тәрҗемәче, Бөек Ватан сугышында катнашучы Гыйлемдәр Рамазановның тууына 100 ел тулуны бәйрәм итү кысаларында үткәрелде хэм шагыйрьнең иҗади мирасын популярлаштыруга, иҗади актив үсеп килүче буынга ярдәм итүгә, Башкортстан Республикасы әдәбиятының иң яхшы үрнәкләрен укуга һәм пропагандалауга кызыксынуны арттыруга юнәлде. Конкурс Гыйлемдар Рамазанов әсәрләрен уку буенча чыгышларны яздыру, шулай ук әсәрләрне декламацияләү видеоязмасын тәкъдим итү. Безнең конкурсның төп максаты әдәби һәм шигъри сәләтләрне ачыклау.

Э хэзер сузне конкурсантларга бирэбез.

**(Конкурсантларның чыгышы)**

Шагыйрьлек тә, пәйгамбәрлек кебек,
Бирелә бары ходай тарафыннан.
Яза шагыйрь , каурый каләм алып
Фәрештәнең ап-ак канатыннан.
Шул каләмен күк нурына манып,
Ак кәгазьгә юллар тезә - тезә,
Халык күңеленә бара шагыйрь –
Мең-мең газапларга түзә-түзә.

Суз шигырьлэре белэн укучылар кунелен яулаган, элеге кондэ яшь буынны шигырь язу хонэренэ ойрэткэн **Расимэ Гимран кызы Ильясовага бирэбез**. Рэхим итегез.

Шигъри тойгы – матурлык тойгысы. Шигырь ул – шул тойгыларны тышка бәреп чыкканы. Тәнгә гимнастика кебек, рухка гимнастика ул шигырь.

Шигъри табигатьле кешеләрне сойләшүеннэн, үзен тотышыннан ук тоеп торасың. Андыйлар белән әнгәмәләшүе дә рәхәт.

Хэзер чыгыш ясаячак кунагыбыз "Чакмагыш чаткылары" агьзасы. **Вахитова Сария Сагит кызы. Рэхим итегез.**

Яхшы шигырь – шул ук дару бит ул,
Димәк, шагыйрь – күңел докторы.
Матур җыр ул, көчле дару кебек,
Йөрәкләргә үтә туп туры.

Дигән язучыбыз Фәнис Яруллин.

Район әдәби-шигъри конурсында катнашучыларга котлау сүзен Чакмагыш узәк биләмә-ара китапханәсенен җитәкчесенэ Гәрәева Алсу Радик кызына бирэбез. Рэхим итегез! Рэхмэт. (Нәтижә ясау өчен сүз жюрига бирелә)

**Жыр._Г.Салимова**______________________________________________

- Хөрмәтле шигырь сөючеләр! Киләчәктә дә тормыштан ямь табып, матур әсәрләр ижат итеп, яңалыкка, алга омтылып яшәгез. Ижат ялкыннарыгыз сүрелмәсен, илһамыгыз кимемәсен! Безне яңадан-яңа шигырьләрегез, акыллы фикерләрегез, үткен сүзләрегез белән сөендереп торыгыз.

Рәхмәт сезгә! Сау булыгыз! Киләсе очрашуларга кадәр!